**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЛӘРКҮЛ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биләркүл ав. **КАРАР**

«12» ноябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Биләркүл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Биләркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 22 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Биләркүл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Озерная урамы, 1-1, Молодежная урамы 1нче йорт, Садовая урамы1-54, Восточная урамы 1 – 16 йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Биләркүл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Спорт урамы 1- 41, Дорожная ур., 1-17, Эшчеләр ур. 1-23, Овражный тыкрыгы 2нче йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2024 елның 22 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Зеленая урамы, 48А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Биләркүл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Южная ур., 1-23, Полевая ур. 1-26, Көнбатыш урамы 2 - 12, Зеленая урамы, 1 – 14 йортта яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

« 2025 елда Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасы буенча белем алучы лардан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы,

- Биләр-Күл авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- урамнарны яктырту җайланмасы»

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биләркүл авылҗирлеге башлыгы В.С.Оренбургов